ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2015 елның 23 ноябре Ямбулат авылы № 2

«2016 елга һәм 2017-2018 еллар план чорына Югары Ослан районының Ямбулат авыл җирлеге бюджеты турында» Югары Ослан районының Ямбулат авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең 2016 нчы елга һәм 2017, 2018 нче елларның планлы чорына бюджеты проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. "2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлы чорына Югары Ослан районының Ямбулат авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан районының Ямбулат авыл җирлеге Советының карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 4 декабрендә 10.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

Үткәрү урыны - Ямбулат авылы, Казан урамы, 2а йорт Ямбулат авылы мәдәният йортында.

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирелә торган адрес: Ямбулат авылы, Центральная урамы, 5 нче йорт, Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Е. Ю. Коноваловага (эш көннәрендә – 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр);

2.5. гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы - 2015 елның 2 декабренә кадәр (тел 36-5-18).

3. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының "Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең 2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлы чорына бюджеты турында" гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән

билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2.Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советына халык алдында тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен, ачык тыңлаулар рекомендацияләрен, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең 2016 елга һәм 2017, 2018 елларның план чорына бюджеты проектын тәкъдим итәргә.

4.Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының "Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең 2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлы чорына бюджеты турында" гы Карары проектын «Волжская новь» район газетасында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.Н. Әхмәтҗанов